Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Околоток-Яңасала авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

07 ноябрь 2019 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче Околоток-Яңасала авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Околоток-Яңасала авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
- Чаллы-Баш авылында юл төзекләндерү (авылга керү, чыгу);
- Яңавыл авылында Киров урамы юлларын төзекләндерү;
- Чаллы-Баш авылындагы суүткәргеч электр сибын алыштыру;
- Околоток-Яңасала авылында суүткәргеч торбаларны алыштыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Фәтхетдинов урамы, 10 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Камалиев И.И.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Камалиев И.И.